Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
Иске Кыязлы авыл җирлеге башкарма комитеты

# КАРАР

№ 10 13.09. 2016 ел

**Референдум үткәрү инициативасы турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьяларына, Татарстан Республикасы Законының 18 статьясына ярашлы 24.04.2004 № 23-ТРЗ «Җирле референдум турында», "Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге уставы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлеге башкарма комитеты карары:

• Җирле референдум үткәрү инициативасы белән:

"2017 елда Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм көндезге уку формасында белем алучы студентлардан тыш, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп, 400 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы:
:

1. Торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
2. Торак пункт чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, су чыгаруны, халыкны ягулык белән тәэмин итүне Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә оештыру:

3. Торак пунктта яшәүчеләрнең күпләп ял итү өчен шартлар тудыру.

ӘЙЕ ЮК

3. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлеге территориясе чикләрендә референдум округын билгеләргә.
4. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлеге башкарма комитетына 18 яшькә җиткән сайлаучылар исемлеген төзергә һәм Иске Кыязлы авыл җирлегенең участок сайлау комиссияләренә раслау өчен тапшырырга.
5. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлеге участок сайлау комиссиясе гамәлдәге законнарга ярашлы рәвештә Иске Кыязлы авыл җирлеге территориясендә референдум үткәрүне оештырырга.
6. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http://Aksubayevo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында да.

Иске Кыязлы авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе: Г. Г. Дәүләтшин